**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2025 **Чирмешән авылы** **№ 279**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елның II яртыеллыгына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләре өчен түләү күләмен раслау турында» 2025 елның 16 июнендәге №178 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156,158 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта тиешле сыйфатта булмаган һәм (яки) билгеләнгән дәвамлылыктан артыграк тәнәфесләр белән гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәткән һәм эшләр башкарган очракта торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елның II яртыеллыгына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләре өчен түләү күләмен раслау турында» 2025 елның 16 июнендәге №178 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтага 9 нчы юлны өстәргә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | айга торак урынның гомуми мәйданының кв.м. | 1,96 |

2. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 01 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Г. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
01.10.2025, № 279

Күпфатирлы торак йортлар белән идарә итү ысулын сайламаган торак урыннар милекчеләре өчен, муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме, күпфатирлы торак йортлар белән идарә итү ысулын сайлаган торак урыннар милекчеләре өчен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар һәм (яисә) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү
КҮЛӘМЕ

| № п/п | Түләү атамасы | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 2,10 |
| 2 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,35 |
| 3 | Йорт эчендәге суүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,6 |
| 4 | Йорт эчендәге электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,5 |
| 5 | Вентиляция каналларын һәм төтен чыгару юлларын тикшерү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 0,30 |
| 6 | Дератизация (дезинсекция) | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 0,15 |
| 7 | Газүткәргечнең йорт эчендәге челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 0,25 |
| 8 | Йорт яны территориясен җыештыру | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,35 |
| 9 | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,96 |

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта
01.10.2025, № 279

## Муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү күләме (наемга база ставкасы)

| Түләү атамасы | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен база ставкасы (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Торак урынны наемга алган өчен түләүнең база күләме | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 8,47 |